
# Кар вальсы

Фирая Зиятдинова сүзләре
Мәсгудә Шәмсетдинова көе




19
S
лар я-ва-зәң-гәр күк-ләр-дән. Ти-яр-ти-
Pno.
25
мәс ке-нә, кы-яр-кый-мас кы-на кар бөр-те-ге
31
ү-бә бит-ләр-дән. а..


37
S
37
Pno.
43
S
43
Pno.
46
S
46
Pno.




Яфрак-яфрак кына,
Ап-ак, ап-ак кына
Карлар ява зәңгәр күкләрдән.
Тияр-тимәс кенә,
Кыяр-кыймас кына
Кар бөртеге үбә битләрдән.

Әй ашкына күңел –
Бәйрәм алды бүген,
Бөтен дөнья актан киенгән.
Күздә – йолдыз нуры,
Йөздә шатлык уйный,
Һәммәсе дә шундый сөенгән.

Зәңгәр бәрхет Һава,
Ап-ак карлар ява, –
Ул карларда пакьлек-сафлык бар.
Юлларым да ап-ак,
Ул юлларда мине
Көтә кебек бары шатлыклар.